«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ
“КҮБӘЛӘК” БАЛАЛАР БАКЧАСЫ”
422065, Татарстан Республикасы,
Олы Кибәче авылы , Ф.Энгельс урамы, 75 йорт
Тел. 42-6-39

“БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКИЙ ДЕТСКИЙ САД “КУБЭЛЭК”
САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНАРЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН”
422065, Республика Татарстан,
с. Большие Кибячи, ул. Ф.Энгельса, 75

Emailkibichisaba.ds@yandex.ru

Принято на заседании педагогического совета № 1
От 28 августа 2025г.

Утверждаю
Заведующий МБДОУ-«Большекибячинский детский сад «Күбәләк»
______ Шакирова Р.Ш.
Приказ№ 47 от 28 августа 2025г.

# 2025-2026нче уку елына тәрбия эшенең календарь тематик планы

| № | Тема | Вакыт | Максат | Йомгаклау чарасы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | **Саубул җәй! Без балалар бакчасына килдек!** | **1-6 сентябрь** | Җәй турындагы белемнәрен киңәйтү, гомумиләштерү. Җәйге табигатькә соклану, сакчыл караш тәрбияләү; тере һәм тере булмаган табигатьтәге үзара бәйләнешләрне аеру; җәй турында алган белемнәрен ныгыту, кызыксынуларын арттыру.Балаларны "1 сентябрь – белем көне" итеп билгеләп үтүен, яше җиткән һәр бала мәктәп бусагасын атлап керүен, мәктәптә күп төрле белем бирүләрен аңлату, яхшы укыр өчен тырыш, түзем, мөстәкыйль, кызыксынучанлык сыйфатларына ия булу. Спорт белән шөгыльләнеп көчле рухлы булырга, авырлыкларны җиңеп чыгарга кирәклегенә төшендерү. Балаларда белем алырга омтылыш тәрбияләү, логик фикерләү сәләтен, хәтерне үстерү,балаларны мәктәп тормышы белән таныштыруны дәвам итү, алган белемнәрен системалаштыру. | **"Җәйге күңелле мизгелләр"** балалар рәсемнәренә күргәзмә 1 сентябрь Белем көне бәйрәмен үткәрү. |
| 2 | **Ел фасыллары. "Исәнме, Алтын көз!" Көзге үзгәрешләр.** | **8-13 сентябрь** | Балаларда көзге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек сыйфатлары тәрбияләү.Балаларның ел фасыллары турында белемнәрен киңәйтү: көзнең характерлы үзенчәлекләре, табигатьтәге үзгәрешләр, кыргый һәм йорт хайваннарының тормышы, кошлар тормышы, кешеләрнең эшчәнлеге;ел фасыллары, ай исемнәре турында белемнәрен ныгыту;табигатьтәге үзгәрешләргә үсемлекләр, җәнлекләр ничек җайлашуы, андагы күренешләргә карата гомуми караш формалаштыру;тере булмаган табигатьтә күзаллауларны киңәйтү; "Көз"темасына сүзлек туплау, активлаштыру, предметның билгесен белдергән сүзләрне җөмләдә дөрес куллану (сүзлек: кызыл, сары, кызгылт-сары);<br>"Көз" рәсеме буенча кечкенә хикәя төзергә өйрәтү; сүз ясау күнекмәләрен үстерү (җил – җилле, ...), күчерелмә мәгънәдәге сүзләр белән таныштыру (алтын көз, кара көз); "Көзге өс киемнәре"темасына сыйфат, фигыль сүзлеген баету, антонимнар куллану. | **"Җәйләр үтте, көзләр җитте" – шигырь бәйрәме.** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **3** | **Көз кучтэнэчләре.** | **15-20 сентябрь** | Яшелчәләр, җиләк-җимешләр турында белемнәрне киңәйтү, системалаштыру, алган белемнәрен уеннар барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү;җиләк-җимеш бакчасы, басу-кыр турында мәгълүмат бирү;предметларны классификацияләү күнекмәләрен ныгыту;сөйләмне билгене белдерүче сүзләр белән баету; балаларның иҗади күзаллауларын, күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен үстерү;игенче турында,аның хезмәтенең авыр һәм мактаулы эш икәнен аңлату,игенче хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү, татар халкының хезмәт сөючән халык икәнен, ялкаулыкның бездә элек – электән зур кимчелек, начар сыйфат саналуын, хезмәт сөю һәркемгә хас сыйфат булырга тиеш икәнен аңлату;яшелчәләргә, җиләк-җимешләргә карата сак караш, аларның витаминнарга бай булуын аңлап, сәламәт тормыш алып бару теләге тәрбияләү;балаларга көзге байлыкның халыкка шатлык, куаныч китерүен төшендерү. | **“Көзге могҗизалар” эти-әниләр белән берлектә оештырылган кул эшләре күргәзмәсе.** |
| **4** | **Икмәк – яшәү терәге.** | **22-27 сентябрь** | Балаларга көзге байлыкның халыкка шатлык, куаныч китерүен төшендерү, бу байлыкларны тудыручы игенчеләр хезмәтенә карата хөрмәт тәрбияләү;игенченең мактаулы һәм авыр хезмәте, икмәкнең нинди юллар аша табынга килүе турында тасвирлап сөйләргә өйрәтүне дәвам итү; татар халкының хезмәт сөючән халык икәнен, ялкаулыкның бездә элек-электән зур кимчелек, начар сыйфат саналуын, хезмәт сөю һәркемгә хас сыйфат булырга тиеш икәнен аңлату;икмәкнең әһәмиятен аңлату, икмәккә сак караш, хөрмәт тәрбияләү. | **Игенче һөнәре белән танышу, амбарга экскурсия.** |
| **5** | **Туган Татарстаным. Яшеллеккә күмелгән туган илем.** | **29 сентябрь-4октябрь** | Балаларда туган авылыбызга карата горурлык хисе тәрбияләү. Туган ил турындагы күзаллауларын киңәйтү. Туып үскән җиргә мәхәббәт тәрбияләү. Балаларда күзаллаулар булдыру: Татарстан – күпмилләтле республика; Казан – республиканың һәм бөтендөнья | **Зөлһиҗә чишмәсенә сәяхәт.** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | татарларының башкаласы;<br>Татарстан Республикасының төп символикасы (флаг, герб, гимн) белән таныштыру; балаларга үз халкыңның бер өлеше булуларын аңлату;<br>ТР ның географик урыны белән таныштыру (картада яки глобуста республиканың территориясен, Кама, Идел елгаларын, Куйбышев, Түбән Кама сусаклагычларын, Кабан күлен, тирә-як күл һәм елгаларын билгеләү);<br>Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның традицияләре, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру; милли бәйрәмнәр (Нәүрүз, Корбан бәйрәме, Сабантуй, Нардуган һ.б.) турында күзаллаулар булдыру. | |
| **6** | **Россия-зур дәүләт. Халыклар бердәмлеге.** | **6-11 октябрь** | Балаларның Россия башкаласы Мәскәү, рус милләте турындагы белемнәрен баету, Россия символикасы турында мәгълүмат бирү; балаларда туган илне ярату, аның белән кызыксыну, туган илгә тугрылык сыйфатлары, башка милләт вәкилләренә карата хөрмәт, дуслык хисләре тәрбияләү. | **“Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел!” –** туган ил, дуслык турында русча шигырьләр белән балалар чыгышы. |
| **7** | **Сабам минем – туган ягым. Минем илем, минем планетам.** | **13-18 октябрь** | Балаларда туган авылыбызга карата горурлык хисе тәрбияләү. Туган ил турындагы күзаллауларын киңәйтү. Туып үскән җиргә мәхәббәт тәрбияләү. Тропик илләр, андагы үсемлекләр, хайваннар, кешеләрнең яшәү рәвеше, шөгыльләре турында күзаллаулар формалаштыру;алган белемнәрне төрле уеннарда куллана белүләренәирешү;әйләнә-тирә белән кызыксынучанлык тәрбияләү.<br>Төньяк, анда яшәүчеләр турында балаларның күзаллауларын үстерү, белемнәрен тирәнәйтү; төньяк табигатенең матурлыгына соклана белү сыйфаты тәрбияләү. | **“Сөмбелә”** бәйрәмен уздыру. |
| **8** | **Китап киңәшчең синең.Мониторинг.** | **20-25 октябрь** | Балаларда китапларга сак караш, хөрмәт тәрбияләү. Китапханәче хезмәтенә карата ихтирам, китапханәдә үз-үзеңне тота белү сыйфатлары тәрбияләү. Китапханә белән турыдан-туры таныштыру аша балаларда | Китапханәгә сәяхәт. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | күзәтүчәнлек, игътибарлылык, эзлекле фикерләү сәләтен үстерү. | |
| 9 | **Әдәплелек дәресләре. Табын янында. Киемнәрдә безне бизиләр.** | **27 октябрь - 1 ноябрь** | Үз-үзеңне әдәпле тоту күнекмәләре тәрбияләү. Халык сәнгате аша балаларда зәвык, матур итеп киенергә теләк тәрбияләү. Тормышта тышкы кыяфәтнең дә мөһимлеген аңлауларына ирешү; өс-баш, аяк киемнәрен чагыштырырга, төркемнәргә аерырга өйрәтү. Милли киемнәргә кызыксыну уяту, үзләренә генә хас булган үзенчәлекләрен ачыклау, төсләрнең берләшүенә игътибар итү.Үзеңне әдәпле тоту күнекмәләре булдыру. Милли ризыклар турындагы белемнәрен тирәнәйтү; балаларны кунакчыл булырга, кунакларга хөрмәт күрсәтергә өйрәтү. | Мәктәп музеена сәяхәт. |
| 10 | **Минем гаиләм,өем, йорт җиһазлары.** | **3-8 ноябрь** | Балаларда гаилә әгъзаларына хөрмәт, ярату хисләре тәрбияләү. Әби-бабайларның кадерле кешеләр булуын төшендерү. Кеше кулы белән эшләнгән әйберләргә карап соклана, хезмәт нәтиҗәләрен күреп горурлана белү хисләре тәрбияләү, электр җиһазларын кулланганда сак булырга өйрәтү. | **“Безнең гаилә”** балаларның рәсемнәре буенча күргәзмә. |
| 11 | **Юлларда иминлек кирәк.** | **10-15 ноябрь** | Балаларда урамда, җәмәгать транспортында, торак зонасында үз-үзеңне тоту культурасын тәрбияләү. Юлларда күзәтүчәнлекне, фикерләү мөстәкыйльлеген игътибарлыкны үстерү. Юл билгеләрен аера белү. Юлда хәвефсезлек кагыйдәләрен өйрәнүне дәвам итү. | **“Юл йөрү кагыйдәләрен, белик барыбызда”** аппликация күргәзмәсе. |
| 12 | **Йорт хайваннары һәм кошлары.** | **17-22 ноябрь** | Балаларда барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлак хисләре тәрбияләү, аларны рәнҗетмәскә кирәклеген төшендерү. Тышкы билгеләренә карап, кыргый һәм йорт хайваннарын аерып күрсәтә белү күнекмәләрен үстерү. | **“Хайваннар дөньясына сәяхәт”** – балалар рәсемнәреннән күргәзмә оештыру. |
| 13 | **Мин олыларга ярдәмче. Әниләр көне.** | **24-29 ноябрь** | Балаларда әниләргә,олыларга карата кадер-хөрмәт тәрбияләү, зирәклек, осталыкларын үстерү, сорауларны игътибар белән тыңлап, аңлап, тулы җавап бирүләренә ирешү, шигырҗләрне сәнгатьле сөйләргә өйрәтү. | Бәйрәм иртәсе үткәрү. |
| 14 | **Кыргый хайваннар** | **1-6 декабрь** | Хайваннар, аларның үзенчәлекләре (тышкы билгеләре, | **“Теремкәй”** рус халык |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **һәм кошлар тормышы.** | | яшәү рәвешләре) һәм файдалары турында белемнәрен баету, системалаштыру; зурлыгы, үз-үзләрен тотышларына, тавышларына карап, кыргый һәм йорт хайваннарын аерып күрсәтә белү күнекмәләрен үстерү;ТР ның Кызыл китабына кертелгән хайваннар төрләре белән таныштыру; хайваннарга карата сак караш, миһербанлылык тәрбияләү.Кошлар турында белемнәрен баету;тышкы билгеләренә карап сыерчык,карга һ.б. Кошларны танырга, исемнәрен әйтергә өйрәтү, кешеләрнең алар турында ничек кайгыртуын күзаллый белүне формалаштыру;балаларның күзәтүчәнлекләрен, кызыксынучанлыкларын, чагыштыра белү күнекмәләрен үстерү;балаларның тасвирлый белү сәләтен үстерү; балаларда кошларга карата сак караш, мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык сыйфатларытәрбияләү. | экиятен сәхнәләштерү. |
| 15 | **Ак ефәктән кыш килде.** | **8-13 декабрь** | Кыш, кар үзенчәлекләре турында балаларның белемнәрен тирәнәйтү;табигатьтә ел фасыллары буенча барган үзгәрешләр турындагы белемнәрен системалаштыру; кышкы табигатькә хас билгеләр турындагы белемнәрне ныгыту; җәнлекләрнең, кошларның кышка ничек җайлашуы турындагы белемнәрне арттыру;кышкы салкын көннәрнең кошлар, хайваннар, кешеләр өчен иң авыр вакыт булуын ачыклау; балаларны әдәби әсәр аша кышның тасвирланышы белән таныштыру; серле табигать күренешләренә соклану хисләре һәм мәхәббәт уяту; балаларда шигырь юллары аша кышкы табигатькә соклану хисләре, мәхәббәт тәрбияләү;табигатькә сак караш, экологик бәйләнешләрне күрә белү сыйфаты тәрбияләү. | **"Килеп җитте матур кыш" – балалар кул эшләренә күргәзмә.** |
| 16 | **Кышлаучы кошлар.** | **15-20 декабрь** | Яңа ел бәйрәме, аңа бездә һәм башка илләрдә ничек әзерләнүләре, нинди әкият геройлары килүе, Кыш бабай, Кар кызы турында күзаллауларны киңәйтү;балаларда бәйрәмнәргә карата уңай мөнәсәбәт, үз фикереңне бер юнәлештә туплый һәм аны башкаларга җиткерә белү | **"Иң матур җимлек"кә конкурс.** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | сыйфаты тәрбияләү. | |
| 17 | **Хуш киләсең ,<br>Яңа ел!** | **22-27 декабрь** | Балаларны Яңа елга багышланган шигырьләр белән таныштыру; сәнгатьле итеп сөйли белүләренә ирешү; кышкы табигатькә соклану хисләре тәрбияләү. | Яңа ел бәйрәме үткәрү. |
| 18 | **Кышкы каникул-күңел ачулар. Балаларның кышкы уеннары.** | **29 декабрь – 10 январь** | Балаларда күтәренке кәеф, шатлык хисләребулдыру;күңел ачуларда катнашасы килү теләге уяту;балаларны күңел ачуларга хәзерлек эшләрендә катнаштыру, бергәләп эшләгән эш нәтиҗәләрен күреп сөенү. | **“Без суыктан курыкмыйбыз”**-ярыш уеннары. |
| 19 | **“Туган телем –татар теле” Әбиемнең серле сандыгы.** | **12-17январь** | Балаларның туган тел-татар теле турындагы мәгълүматларын тирәнәйтү, баету. Туган телебезне ярату, зурлау, аңа соклану хисләре тәрбияләү. Балаларда әбиләргә карата мәхәббәт,ихтирам, хөрмәт хисләре, игътибарлылык тәрбияләү;Әбиләргә һәрвакыт ярдәмгә килү, аларга булышып тору теләге тәрбияләү. | **“Кием кешене бизи”**-Татарстан Республикасындагы төрле халыкларның милли киемнәре – әти-әниләр белән берлектә ясалган рәсем күргәзмәсе. |
| 20 | **Ял итү өчен җәмәгать урыннары. Үз-үзеңне тоту кагыйдәләре(театр, концерт залы, цирк һ.б.)** | **19- 24январь** | Театр, концерт залы, цирк һ.б. җәмәгать урыннары турында балаларның белемнәрен киңәйтү; җәмәгать урыннарында үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре белән таныштыру;башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышын күзәтү, чагыштыру, каршы кую, бәяли белү күнекмәләрен үстерү. | Клубка экскурсия. |
| 21 | **Әти-әни һәм мин – сәламәт гаилә. Саулык зур байлык. Спорт –сәламәтлек чыганагы.** | **26-31январь–** | Балаларда хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ формалаштыру;<br>яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, уеннар оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү;<br>хәрәкәтләнү тәҗрибәсен баету;<br>хәрәкәтле уеннарда җитезлек, тизлек, сыгылмалылык, чыдамлылык сыйфатларын үстерү;балаларның хоккей буенча “Ак Барс”, футбол буенча “Рубин”, баскетбол буенча “УНИКС” командалары турындагы күзаллауларын киңәйтү;физик культура, спорт белән шөгыльләнергә теләк уяту; сәламәт яшәү рәвешен тәшкил итүче (актив хәрәкәт, йокы, ял, дөрес туклану һ.б.) һәм сәламәтлеккә зарар китерүче факторлар | **“Сәламәт булыйк!”.** Күңел ачу кичәсе. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | турындагы күзаллауларны киңәйтү. | |
| 22 | **Заманча әкиятләр.** | **2-7 февраль** | Заманча мультфильмнарны таный белергә,аларның эчтәлеге буенча үз фикерләрен башкаларга җиткерә белергә өйрәтү. Балаларда яхшы һәм начар төшенчәләрен формалаштыру, үзен һәм башкаларны дөрес бәяли белергә өйрәтүне дәвам итү. Бергә уйный торган иптәшләренең фикере белән исәпләшә, бәхәсләрне гадел хәл итә белүчәнлек тәрбияләү. | **“Әкиятләр илендә”**балаларның рәсемнәреннән күргәзмә Заманча әкиятне сәхнәләштерү. |
| 23 | **М.Җәлил – халык улы.** | **9-14 февраль** | М.Җәлил турында балаларның белемнәрен баету, аның әсәрләре белән танышуны дәвам итү; герой-шагыйрьгә карата бәяләмә бирү, аның батырлыгына соклану хисләре тәрбияләү;балаларда патриотик хисләр, Ватанны саклау теләге тәрбияләү. | **“Муса Җәлил – бөек шагыйребез” –** шагыйрьнең әсәрләрен сәхнәләштерү, бәйрәм кичәсе үткәрү. |
| 24 | **Батырлыкта-матурлык.** | **16-21 февраль** | Балаларда кыю, батыр солдат булу теләге уяту; әтиләре, абыйлары белән горурлану хисе тәрбияләү; Ватанны саклаучылар турындагы күзаллауларын киңәйтү; җирне, күкне, диңгезне саклаучылар турында белем бирү, аларның мөһимлеген аңлату;илебезнең тынычлыгын саклаучы солдатларга карата патриотик хисләр, Ватанны саклау теләге тәрбияләү. | Әтиләр өчен бәйрәм кичәсе. |
| 25 | **Мин кеше. Мин шәхес. Минем хокукларым.** | **23-28 февраль** | Балаларда әхлакый сыйфатлар, әти-әнигә хөрмәт тәрбияләү;балаларның гаиләдәге хокуклары турындагы белемнәрен ныгыту, аларның ялга, уенга хокуклы булуларын аңлату;балаларга дус булырга кирәклеген төшендерү, аларда дуслык, әхлаклылык хисләре тәрбияләү; кеше бер-берсе белән нинди милләттән булуына карамастан, туганнарча аралашып яшәүгә хокуклы булу төшенчәсен бирү.Бар кеше дә яхшы тормышка хокуклы, җирдәге тынычлык кешеләрнең үзләреннән тора, бар халыклар да аңлашып, иркле, тигез хокуклы булып, бер-берсе белән дус булып, аралашып яшәргә тиеш төшенчәләрен аңлауларына ирешү. | Әти-әниләр белән берлектә **“Минем яратуга һәм кайгыртуга хокукым бар”** темасына рәсем күргәзмәсе. |
| 26 | **“Яз килә, яз килә,** | **2-7 март** | Балаларда әниләргә карата мәхәббәт,ихтирам, хөрмәт хисләре, игътибарлылык тәрбияләү.Әниләргә һәрвакыт | **“Кадерле әнием!”** әниләр өчен кичә. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **елмаеп кояш көлә!” Әниләр бәйрәме.** | | ярдәмгә килү, аларга булышу теләге тәрбияләү. Әниләрнең дөньяда иң кадерле, иң газиз кеше икәнен аңлауларына ирешү. | |
| **27** | **Сулар ага, бозлар китә, кошлар кайта җылы яклардан.** | **9-14 март** | Туган ягыбызда була торган язгы табигать күренешләренә соклану хисләре тәрбияләү; максатчыл күзәтү аша балаларны язгы табигать күренеше белән таныштыру; табигатьтәге бәйләнешләрне аңлата белү күнекмәләрен камилләштерү;әйләнә-тирә дөньяга эстетик мөнәсәбәт формалаштыру; рәсем буенча табигатьтәге үзгәрешләр турында сөйли белүләренә ирешү;яз турында эндәшләр, тизәйткечләр, әйтенүләр, сынамышлар өйрәтү;балаларда яз турында белемнәрен мөстәкыйль эшчәнлектә иҗади куллана белү күнекмәләрен үстерү;балаларда суган үстерү теләге тудыру, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү;суганның файдалы яшелчә икәне турында төшенчә бирү; суган үстерү турында белемнәрен тулыландыру; табигатькә карата аңлы караш, экологик культура тәрбияләү. | Сыерчык оялары ясау (этиләр белән берлектә). |
| **28** | **Су яшәү чыганагы.** | **16-21 март** | Балаларның су, аның үзенчәлекләре, табигатьтә була торган үзгәрешләр турында белемнәрен киңәйтү; яңгырның каян килеп чыгуын аңлату; гади тәҗрибәләр һәм уеннар аша балаларның су үзенчәлекләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү; яшәү чыганагы булган суга сак караш тәрбияләү; табигатькә соклана һәм аның гүзәллеген күрә белергә өйрәтү. | Яз турында эндәшләр, тизәйткечләр, әйтенүләр, сынамышлар бәйгесе. |
| **29** | **Куркынычсызлык. Уттан саклан.** | **23-28 март** | Ут чыгу куркынычы булган әйберләр белән сак булу сыйфаты тәрбияләү. Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән танышуны дәвам итү, янгын чыгу очрагында үзләрен дөрес тоту күнекмәләрен ныгыту. Матур әдәбият аша балаларда саклык, игътибарлылык сыйфатлары тәрбияләү. | **“Ут кешенең дусты һәм дошманы”** рәсем күргәзмәсе. |
| | **“Юлда йөрсәң бул** | | Юл билгеләрен аера белү. Юлда хәвефсезлек | Физкультурный досуг |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **30** | **өлгер, юл кагыйдәсен нык бел!" Юл йөрү кагыйдәләре, билгеләре.** | **30 март – 4 апрель** | кагыйдәләрен өйрәнүне дәвам итү Балаларда урамда, җәмәгать транспортында, торак зонасында үз-үзеңне тоту культурасын тәрбияләү. Юлларда күзәтүчәнлекне, фикерләү мөстәкыйльлеген игътибарлыкны үстерү. | |
| **31** | **Галәм киңлекләре.** | **6-11 апрель** | Балаларда беренче очучы Ю.Гагарин белән танышу аша, илебезгә карата горурлык хисләре тәрбияләү;<br>Галәм турындагы белемнәрен системалаштыру;<br>Кояш системасы, планеталар турында элементар белешмә бирү, алар турында күбрәк беләсе килү теләге уяту; Космонавтика көне турында белемнәрен формалаштыру;тирә-юньне, табигатьне аңларга һәм сакларга сәләтле, актив, иҗади шәһес тәрбияләү. | **"Космоска сәяхәт"** күңел ачу чарасы. |
| **32** | **Урман-җиребезнең матурлыгы, байлыгы.** | **13-18 апрель** | Балаларда урманга һәм аның байлыкларына сак караш тәрбияләү; кешеләр тарафыннан табигатьне сакларга кирәклеге турында нәтиҗә чыгара белү, логик фикер йөртә белү сәләтен үстерү; урман, андагы тереклек турындагы белемнәрен тирәнәйтү, мул табигатьнең кеше тормышында әһәмиятен аңлату; Кызыл китапка кертелгән хайван һәм үсемлекләрне кызгану, алар өчен борчылу хисләре уяту; сирәк калган һәм югалып бара торган хайваннар, үсемлекләр турындагы китап белән таныштыру, аның әһәмиятен аңлату; балаларда игътибарлылык, әйләнә-тирә табигатькә, урманга карата сакчыллык, миһербанлылык сыйфатлары, экологик культура тәрбияләү;табигатьтәге үзара мөнәсәбәтләрне күрә белү сәләтен үстерү;<br>Татарстан җирлегендә үсә торган урман үсемлекләре турында белемнәрен камилләштерү. | Кул эшләре күргәзмәсе. |
| **33** | **Г.Тукай безнең күңелләрдә.** | **20-25 апрель** | Г.Тукайның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыру; балаларда Г.Тукайның күпкырлы иҗатына кызыксыну уяту,таныш әдәби сюжетлар буенча балаларның Г.Тукай иҗаты буенча алган белемнәрен камилләштерү;<br>шагыйрьгә,шагыйрьнең иҗатына карата мәхәббәт, | **"Без тукай оныклары"** кичә. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | ихтирам хисләре тәрбияләү;Г.Тукай әкиятләре, шигырьләре аша балаларда матур әдәбият белән кызыксыну, аларны укырга теләк тәрбияләү, тырышлык, игътибарлылык, сабырлык кебек сыйфатлар тәрбияләү. | |
| 34 | **Хезмәт төбе-хәзинә.** | **27апрель -2май** | Балаларның өлкәннәр хезмәте, аларның һөнәрләре турында белемнәрен киңәйтү, алар хезмәтенең мөһимлеген аңлату;төрле һөнәр ияләренә карата кызыксынучанлыкларын үстерү;балаларда һөнәр остала-рының матур эшләренә соклану, аларның хезмәтенә хөрмәт, горурлык хисләре тәрбияләү. | **“Мин үскәч кем булам?”** рәсем күргәзмәсе. |
| 35 | **Җиңү алып килгән яз.** | **4-9 май** | Сугышчыларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында балаларның белемнәрен арттыру; Бөек Ватан сугышы геройлары , аларның күрсәткән батырлыклары турында күзаллауларын киңәйтү; Туган ил һәм дөньядагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкларын үстерү; балаларда Ватанга, туган якка, туган телгә мәхәббәт, патриотик хисләр, кыю һәм батыр булу теләге тәрбияләү. | **“Һәйкәлләргә барыйк..”** кичә. |
| 36 | **Язучылар иҗаты. (А.Алиш, Р.Миңнуллин һ.б.)** | **11-16 май** | А.Алиш һәм Р.Миңнуллин әсәрләренә кызыксыну уяту. Язучы әсәрләре аша балаларда уңай сыйфатлар тәрбияләү. Язучыларның тормыш юлларын һәм иҗатын өйрәнү. | **“Сертотмас үрдәк”** экиятен сәхнәләштерү. |
| 37 | **Мониторинг. Тиздән –җәй!** | **18-23май** | Җәй турында күзаллауны киңәйтү, белемнәрен ныгыту; табигатькә аңлы караш, экологик культура тәрбияләү; балаларга мәктәп турында мәгълүмат бирү, аларда белем алуга омтылыш уяту;сөйләм телен, фикерләү сәләтен, танып белү активлыгын үстерү;мәктәпкә карата уңай караш, укыйсы килү теләге тәрбияләү. | Авылның ял паркына сәяхәт. |
| 38 | **Бүлмә гөлләре. Чәчәкләр тормыш яме. “Сау бул, бакча”.** | **25-30 май** | Балаларда барлык тереклек ияләренә карата шәфкатьлелек, табигатькә сак караш тәрбияләү. Балаларның туфрак турындагы күзаллауларын киңәйтү, бүлмә гөлләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыруны дәвам итү. | **“Хуш, сөекле бакчабыз!”** – мәктәпкә әзерлек төркеменең чыгарылыш кичәсе. |